Чистай муниципаль районының
Булдырь авыл җирлеге Советы

Карары

2021 елның 14 июле №13/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Булдырь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Булдырь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында мәгълүмат тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районының 2021 елның 11 июнендәге 2 номерлы «Булдырь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча комиссиясе бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Булдырь авыл җирлеге советы

КАРАР ИТТЕ

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Булдырь авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 июнендәге 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Булдырь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә, «Шәхси торак төзелеше зонасы» Ж1 территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Змеево авылы, Бакча ур., з/у 22 чикләрендәге территорияне, шул исәптән кадастр номеры 16:42:200301:758 булган, 1951 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген, «Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона» ОД1 төзелеш зонасына кертү өлешендә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Булдырь авыл җирлеге
башлыгы Н.Н. Воляков

2021 елның 14 июлендәге
13/1 номерлы карарына кушымта

Чистай муниципаль районының «Булдырь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территорияләрен шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

